КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 2 апрель г.Казань № 205

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Салым түләүчеләргә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурыч барлыгы (булмау) турында мәгълүмат бирү эшен оештыру хакында» 2020 ел, 11 декабрь, 1127 нче карарына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Салым түләүчеләргә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурыч барлыгы (булмау) турында мәгълүмат бирү эшен оештыру хакында» 2020 ел, 11 декабрь, 1127 нче карарына, 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2. Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгын Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарының дәүләт һәм муниципаль түләүләр турындагы дәүләт мәгълүмат системасы белән соратулар администраторы буларак мәгълүмати үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә торган итеп расларга.

Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтәнең министрлыгына Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарын ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең төбәк системасына тоташтыруны тәэмин итәргә, бу Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурыч барлыгы (юклыгы турында) хакында белешмәләр алу максатларында эшләнә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин